КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 июнь г.Казань № 579

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче; 2016 ел, 19 август, 576 нчы, 2016 ел, 5 декабрь, 892 нче, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы, 2020 ел, 31 гыйнвар, 51 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1234 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның тугызынчы абзацына «һәм (яисә) локаль норматив акт белән» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннары бирү тәртибендә:

1.7 пунктның беренче абзацына «һәм/яисә хезмәт шартнамәләре» сүзләреннән соң «йә локаль норматив актлар» сүзләрен өстәргә;

1.10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр җирле үзидарә органнарында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куелган гражданнар исәпкә куелу датасыннан соң бер ел эчендә торак урын сайласа, яңадан теркәп кую таләп ителми.»;

әлеге карар белән расланган Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм срокларын билгеләү тәртибендә:

7 пунктның беренче абзацында «бала туган вакытка» сүзләреннән соң «, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнарның түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм срокларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 июнь, 579 нчы карары редакциясендә)

## Түләүләрне кичектереп торуның дәвамлылыгын билгеләү

| Башлангыч кертем күләме ( торак урын бәясенең %ы) | Квоталар категориясе | Фатирларны сайлау рәвеше | Бер гражданга исәплэгәндә гаиләнең уртача айлык кереме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | МКБ азрак[1] | МКБ алып 0,5 РКБ кадәр[2] | 0,5 РКБ алып РКБ кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Минималь 1000 сум | кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар | квота чикләрендә әлеге категория буенча конкурс | 17 яшь | 12 яшь | 9 яшь |
| Чираттагы елга «Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итү» программасы гамәлгә ашырыла торган алдагы елның IV кварталына Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлык тарафыннан раслана торган торакның гомуми мәйданының 1 кв.метрының уртача базар хакы күләменең кимендә 11%ы күләмендә айлык тупланманы һәм фатирны сайлау вакытына торак урын бәясенең кимендә 10% гамәлгә ашыру | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре | килешү төзү срогы буенча бюджетчылар өчен квотаның 50% ын бүлү | 17 яшь | 12 яшь | 9 яшь |
| 10 % | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре / социаль ипотеканы финанслауда катнашучы оешмалар хезмәткәрләре | оешмалар квотасы чикләрендә конкурс һәм бюджетчылар өчен 50% квота | 17 яшь | 13 яшь | 9 яшь |

[1]Минималь куллану бюджетының бәясе.
[2]Рациональ куллану бюджетының бәясе.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 20 % | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре / социаль ипотеканы финанслауда катнашучы оешмалар хезмәткәрләре | оешмалар квотасы чикләрендә конкурс һәм бюджетчылар өчен 50% квота | 18 яшь | 14 яшь | 10 яшь |
| 30 - 90%тан артык түгел | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре / социаль ипотеканы финанслауда катнашучы оешмалар хезмәткәрләре | оешмалар квотасы чикләрендә конкурс һәм бюджетчылар өчен 50% квота | 19 яшь | 15 яшь | 11 яшь |